КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 октябрь

г.Казань

№ 876

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 20 февраль, 99 нчы карары белән расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, журналистика өлкәсендә иҗади хезмәткәрләрнең кадрлар потенциалын ныгыту чараларын оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләре, дәүләт корпорацияләре (компанияләре) һәм гавами-хокукый компанияләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, журналистика өлкәсендә иҗади хезмәткәрләрнең кадрлар потенциалын ныгыту чараларын оештыруга һәм уздыруга,

сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләре, дәүләт корпорацияләре (компанияләре) һәм гавами-хокукый компанияләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 20 февраль, 99 нчы карары белән расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, журналистика өлкәсендә иҗади хезмәткәрләрнең кадрлар потенциалын ныгыту чараларын оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләре, дәүләт корпорацияләре (компанияләре) һәм гавами-хокукый компанияләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«яшәү хезмәтләренә чыгымнар – штаттагы хезмәткәрләргә, проектлар һәм чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән белгечләргә торак арендасын түләү.»;

1.12 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$C = P_1 + P_2 + P_3 + P_4 + P_5 + P_6 + P_7 + P_8 + P_9$,»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_9$ – яшәү хезмәтләренә чыгымнар – штаттагы хезмәткәрләргә, проектлар һәм чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән белгечләргә торак арендасын түләү.»;

түбәндәге редакциядәге унөченче абзац өстәргә:

«Бу пунктта күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар Россия Федерациясе законнары нигезендә, шулай ук бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин